**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

______09.09.2020_________ Казан шәһәре №______405________

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277 номерлы боерыгы белән расланган Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

**Боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2014 елның 8 августындагы 289 номерлы, 2015 елның 19 мартындагы 134 номерлы, 2015 елның 3 июлендәге 317 номерлы, 2016 елның 16 мартындагы 70 номерлы, 2016 елның 2 июнендәге 176 номерлы, 2017 елның 2 июнендәге 172 номерлы, 2018 елның 19 апрелендәге 172 номерлы; 2018 елның 13 июлендәге 335 номерлы, 2019 елның 29 октябрендәге 545 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Дәүләт мәгълүмат ресурслары секторына әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны министр урынбасары А.Д.Шәмсиевка йөкләргә.

**Министр** **М.Р. Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
_09.09.2020__№ _405__
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның
26 августындагы 277 номерлы боерыгы белән расланган Кара металл, төсле
металл ватыкларын әзерләү, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3.1 пунктның икенче абзацында түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Гаризалар кабул итү графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш, Министрлыкның эш сәгатьләрендә.»;

1.3.4 пунктчада:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык бинасында урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары аша. Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) дәүләт хезмәте күрсәтү турында булган белешмәләрне үз эченә ала;»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында – http://mert.tatarstan.ru. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә, «Интернет»челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми басылып чыгу чыганакларын да күрсәтеп) «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.5 пунктта:

өченче абзацта «Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округыы) шәһәр яки авыл җирлегендә» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның» сүзләрен «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру

турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга»;

2 бүлектә:

2.1 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «99-ФЗ номерлы федераль закон» сүзләрен «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 99-ФЗ номерлы федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «ТР Министрлар Кабинетының 325 номерлы карары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 23 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәнең 4.1.38 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында « РФ Хөкүмәтенең 826 номерлы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Лицензиянең типик формасын раслау турында» 2011 елның 6 октябрендәге 826 номерлы карары» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының җиденче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2.4 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «294-ФЗ номерлы федераль закон» сүзләрен «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «РФ Хөкүмәтенең 1287 номерлы карары» сүзләрен «Кара һәм төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү турында» 2012 елның 12 декабрендәге 1287 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктның «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпләр» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмаларның» сүзләренә алмаштырырга;

2.7 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгәндә;

2. әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар тулысы белән тапшырылмаганда»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«99-ФЗ номерлы федераль законның 13, 18 статьялары»;

2.8 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

лицензия бирү турында тапшырылган гаризада һәм (яки) аңа теркәлә торган документларда дөрес булмаган яки ялган мәгълүмат булуы;

тикшерү барышында лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә туры килмәве ачыкланганда;

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«99-ФЗ номерлы федераль законның 14, 18 статьялары»;

2.9 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «РФ Салым кодексы» сүзләрен «Россия Федерациясе Салым кодексы» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык булырга тиеш түгел. Аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указының 1 пункты»;

2.14 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, һаваны кондиционерлау системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

Катнашу урыны Татарстан Республикасы Телекоммуникацияләрнең дәүләт интеграция системасына тоташтырылган электрон мәгълүмат киоскы (инфомат) белән җиһазландырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, объектлардан һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

объектларга һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалана алу шартлары;

объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль рәвештә яки хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр ярдәмендә хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

объектларга керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга объектларда ярдәм күрсәтү;

инвалидларның объектлардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

хезмәттән файдалану өчен кирәкле, тавыш ярдәмендә һәм күрсәтмә мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм Брайль рельеф-нокта шрифтлары белән һәм контраст фонында башкарылган текстлы һәм графиклы башка мәгълүматны кабатлап күрсәтү, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене, шулай ук ишарә телен белә торган башка затны кертү;

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль законның 15 статьясының 7 пункты нигезендә, махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булган очракта, озата йөрүче этне объектка кертү;

хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга алар өчен үтемле формада хезмәт күрсәтү тәртибен аңлатуга, аны күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүгә, инвалидларны кабинетларның урнаштырылу тәртибе белән таныштуыруга, хезмәттән файдалану өчен кирәкле гамәлләр эзлеклелегенә бәйле кирәкле ярдәмне күрсәтү;

күрү буенча инвалидлар өчен Россия Икътисадый үсеш министрлыгының, ведомство буйсынуындагы органнар һәм оешмаларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларыннан файдалана алу шартлары;

инвалидларның яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, электрон рәвештә дәүләт хезмәтләреннән файдалана алу мөмкинлеге;

кирәк булганда инвалид яшәгән урын буенча яки дистанцион режимда хезмәт күрсәтү мөмкинлеге;

хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәттән файдалануга комачау итә торган каршылыкларны үтүдә кирәкле башка ярдәм күрсәтү.

2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.»;

2.15 пункттагы «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан Регламент бозылу очракларына карата нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы.»;

«Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «880 номерлы ТР МК карары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы ТР МК карары» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

3.2 пунктның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3.5.3 пунктның алтынчы абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3.5.4 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентның 3.5.2-3.5.4 пунктларында билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3.5.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, рәсми мөрәҗәгатьләр кергән мизгелдән башлап биш эш көне эчендә белешмәләр белән тәэмин итүче затлар тарафыннан җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла.»;

3.5.7 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентның 3.5.6-3.5.7 пунктларында билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3.5.8 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.5.8. Планнан тыш документар тикшерү нәтиҗәләре буенча бүлек белгече ике нөсхәдә тикшерү акты, документлар проектларын рәсмиләштерә һәм килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерүгә юнәлдерелгән тикшерү акты, документлар проектлары.»;

3.5.9 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.5.9. Бүлек башлыгы, Идарә башлыгы, юридик бүлек башлыгы лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында боерык проектын (яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында документлар) килештерә, ул министрга (министр урынбасарына) кул куюга җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар проектлар килештерүгә алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензия бирү турында министрга (министр урынбасарына) кул кую өчен җибәрелгән боерык проекты.»;

3.5.10 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.10. Министр (министр урынбасары) лицензияне яңадан рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерелгән лицензияне (яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турындагы документларны) имзалый.»;

3.5.11 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.11. Бүлек белгече, лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында кул куелган боерык нигезендә, лицензия турындагы белешмәләрне лицензияләр реестрына кертә.»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Агымдагы контрольлек Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив

хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр бирү сроклары һәм тәртибе үтәлешенә.»;

5.2 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;»;

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип танылган очракта, әлеге Административ регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.»;

1, 2 нче кушымталарда «исеме, ата исеме» сүзләреннән соң «(соңгысы – булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

1-6 нчы кушымталарда «Ф.И.А.» сүзләрен «Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга; 1, 2 һәм 6 нчы кушымталарда «ФИО» сүзләрен «Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга.